| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БАВЛЫ» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
| 31.01.2022 | №11 |

Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» карары нигезендә Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Баулы шәһәрендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен, 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә, 2022 елның 1 февраленнән 6964,68 суммасында билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче Д.Л. Бакиров

«Баулы шәһәре»
муниципаль берәмлеге
Башкарма комитетының
2022 елның ____ гыйнварындагы
___ номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасының Баулы шәһәрендә 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| № п/п | Хезмәт исеме | Хезмәт бәясе (сумнарда) |
|---|---|---|
| 1. | Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | – |
| 2. | Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3880,70 |
| 3. | Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1516,29 |
| 4. | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1567,69 |
| | Барлыгы: | 6964,68 |

«Баулы шәһәре»
муниципаль берәмлеге
Башкарма комитетының
2022 елның ____ гыйнварындагы
___ номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасының Баулы шәһәрендә 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| № п/п | Хезмәт исеме | Хезмәт бәясе (сумнарда) |
|---|---|---|
| 1. | Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | – |
| 2. | Мәетне кәфенләү | 1369,17 |
| 3. | Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2596,35 |
| 4. | Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка күчерү | 1471,31 |
| 5. | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1527,85 |
| | Барлыгы: | 6964,68 |